**УКАЗ**
ПРЕЗИДЕНТА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ПРЕЗИДЕНТЫ
**УКАЗЫ**

# Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына һәм резерв составына үзгәрешләр кертү турында

Аерым затларның башка эшкә күчүләре белән бәйле рәвештә, Татарстан Республикасында яшәүче Россия Федерациясе гражданнарын оешкан төстә һәм үз вакытында хәрби хезмәткә чакыруны тәэмин итү максатларында, «Хәрби бурыч һәм хәрби хезмәт турында» 1998 елның 28 мартындагы 53-ФЗ номерлы Федераль законның 26 һәм 27 статьялары нигезендә **карар бирәм:**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре турында» 2016 елның 25 мартындагы ПУ-282 номерлы Указы белән (Татарстан Республикасы Президентының 2016 елның 22 июнендәге ПУ-538 номерлы, 2016 елның 29 сентябрендәге ПУ-884 номерлы, 2016 елның 20 декабрендәге ПУ-1151 номерлы, 2017 елның 31 мартындагы ПУ-259 номерлы, 2017 елның 24 июнендәге ПУ-537 номерлы, 2017 елның 30 сентябрендәге ПУ-868 номерлы, 2017 елның 29 декабрендәге ПУ-1177 номерлы, 2018 елның 29 мартындагы ПУ-272 номерлы, 2018 елның 23 июнендәге ПУ-459 номерлы, 2018 елның 25 сентябрендәге ПУ-688 номерлы, 2018 елның 19 ноябрендәге ПУ-779 номерлы, 2019 елның 4 февралендәге ПУ-62 номерлы, 2019 елның 29 мартындагы ПУ-188 номерлы, 2019 елның 27 июнендәге ПУ-371 номерлы һәм 2019 елның 27 сентябрендәге ПУ-577 номерлы указлары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) расланган Татарстан Республикасының муниципаль районнарындагы һәм шәһәр округларындагы хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре (алга таба – хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре) составына һәм резерв составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составыннан чыгарырга:

Актаныш муниципаль районы буенча Л.Ф. Нурлыеваны;

Алексеевск муниципаль районы буенча В.А. Яковлевны, Д.А. Гыйлаҗевны;

Бөгелмә муниципаль районы буенча Ш.Ж. Сөендековны;

Зәй муниципаль районы буенча В.В. Архиповны;

Лаеш муниципаль районы буенча Н.Ю. Шириязданованы;

Лениногорск муниципаль районы буенча Н.Р. Залаковны;

Ютазы муниципаль районы буенча М.В. Сибагатовны;

б) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре составына кертергә:

Актаныш муниципаль районы буенча Габделхәев Илшат Илфат улын – Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен, аны комиссия рәисе итеп расларга;

Алексеевск муниципаль районы буенча: Сөләйманов Ривкать Бари улын – Татарстан Республикасы Алексеевск муниципаль районының мәгариф бүлеге башлыгын, Юнысов Руслан Рамис улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Алексеевск районы буенча бүлеге башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны;

Бөгелмә муниципаль районы буенча Сөләйманова Ирина Игоревнаны – Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсенең әйдәүче белгечен;

Зәй муниципаль районы буенча Минһаҗев Рамис Мөхәммәтдин улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Зәй районы буенча бүлеге полиция участок уполномоченныйлары һәм балигъ булмаганнар эшләре бүлеге башлыгын;

Лаеш муниципаль районы буенча Гыйрфанова Эльвира Рифан кызын – Татарстан Республикасы Лаеш районы Хәрби комиссариаты бүлекчәсе (гражданнарны хәрби хезмәткә әзерләү һәм чакыру) бүлекчәсе фельдшерын, аны комиссия секретаре итеп расларга;

Лениногорск муниципаль районы буенча Михайлова Зөлфия Габделхамәт кызын – Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесен, аны комиссия рәисе итеп расларга;

Ютазы муниципаль районы буенча Клещевников Евгений Анатольевичны – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Ютазы районы буенча бүлеге башлыгын;

в) Теләче муниципаль районы буенча хәрби хезмәткә чакыру комиссиясе әгъзасы З.З. Ибраһимовның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Теләче муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге башлыгы»;

г) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре резерв составыннан чыгарырга:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы буенча Р.Ш. Харисламованы;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Комсомол районы буенча Э.Г. Вәлиеваны;

Әлмәт муниципаль районы буенча М.А. Алиевны;

Бөгелмә муниципаль районы буенча Э.Н. Ризвановaны, И.Г. Чернованы;

Зәй муниципаль районы буенча Л.Г. Федотованы;

Кукмара муниципаль районы буенча Р.Х. Галиеваны, А.Н. Гаянованы;

Лаеш муниципаль районы буенча Н.Ф. Фәрхуллинаны;

Мамадыш муниципаль районы буенча В.П. Новиковны;

Спас муниципаль районы буенча Р.Р. Закированы;

Тәтеш муниципаль районы буенча А.С. Голодны;

Теләче муниципаль районы буенча Д.С. Гыйниятуллинны, А.А. Нурмөхәммәтовны;

д) хәрби хезмәткә чакыру комиссияләре резерв составына кертергә:

Казан шәһәре муниципаль берәмлегенең Совет районы буенча Сәмигуллин Марат Фаикъ улын – Казан шәһәренең «9 номерлы «Дербышки» стоматология поликлиникасы» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте табиб-стоматологын (килешү буенча), аны хәрби хезмәткә чакырылучы гражданнарны медицина буенча таныклау эшенә җитәкчелек итүче табиб итеп расларга;

«Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлегенең Комсомол районы буенча Скибина Татьяна Александровнаны – «Чаллы шәһәре» муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының Комсомол районы администрациясе башлыгы урынбасарын;

Әлмәт муниципаль районы буенча Сөнгатуллин Айнур Илдус улын – Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының Әлмәт районы буенча бүлеге җәмәгать тәртибен саклау бүлеге өлкән инспекторын;

Бөгелмә муниципаль районы буенча Булгаков Морат Рамил улын – Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын, аны комиссия рәисе итеп расларга, Нуруллина Лилия Наил кызын – Бөгелмә муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе кадрлар бүлеге белгечен;

Зәй муниципаль районы буенча Бушуев Александр Сергеевичны – Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының Яшьләр эшләре идарәсе башлыгын;

Кукмара муниципаль районы буенча Әхмәтшина Айгөл Мәсхут кызын – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын, аны комиссия рәисе итеп расларга, Иванова Ирина Владимировнаны – Кукмара муниципаль районы Башкарма комитеты Мәгариф идарәсе башлыгы урынбасарын;

Лаеш муниципаль районы буенча Сакаева Адилә Ерик кызын – Лаеш үзәк район хастаханәсе фельдшерын, аны комиссия секретаре итеп расларга;

Мамадыш муниципаль районы буенча Куренин Михаил Петровичны – Татарстан Республикасы Мамадыш районы Хәрби комиссариаты бүлекчәсе (мобилизация ресурсларын планлаштыру, билгеләү, әзерләү һәм исәпкә алу) башлыгы вазыйфаларын вакытлыча башкаручыны, аны комиссия рәисе урынбасары итеп расларга;

Спас муниципаль районы буенча Савинов Евгений Викторовичны – Спас муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын, аны комиссия рәисе итеп расларга;

Тәтеш муниципаль районы буенча Нестерова Оксана Борисовнаны – Тәтеш муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге әйдәүче белгечен;

Теләче муниципаль районы буенча Кәримуллин Ренас Рамис улын – Теләче муниципаль районының «Олимп» яшьләр үзәге директорын (килешү буенча), Хәмидуллин Илнур Хаҗинур улын – Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасарын, аны комиссия рәисе итеп расларга.

2. Әлеге Указ аңа кул куйган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты** **Р.Н. Миңнеханов**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫ АППАРАТЫ * АППАРАТ ПРЕЗИДЕНТА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2020 ел, 11 гыйнвар
№ ПУ-6